ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 52-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 52-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 195-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 2 пунктта «, мондый процентлар инвестиция стадиясендә түләнгән булса һәм мондый кредитларга һәм заемнарга, облигация заемнарын да кертеп, турыдан-туры дәүләт ярдәме чаралары бирелмәгән булса»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) инвестиция проектының төп объектын (инвестиция проектының төп объектларын) булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү өлешендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә, мондый процентлар инвестиция стадиясендә түләнгән булса һәм мондый кредитларга һәм заемнарга, облигация заемнарын да кертеп, турыдан-туры дәүләт ярдәме чаралары бирелмәгән булса»;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чаралары устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының (офшор компанияләренең), шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) хуҗа булу өчен файдаланыла торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләтнең яисә территориянең чит ил юридик затларының, турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аркылы) катнашу өлеше барлыгы 25 проценттан артык булган Россия юридик затларына бирелми.»;

3) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Инвестиция проекты аның төп объекты буларак (төп объектлары буларак) транспорт, энергетика инфраструктурасы объектын, коммуналь, социаль яисә цифрлы инфраструктура объектын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне һәм (яисә) модернизацияләүне күздә тотса, мондый инвестиция проектына карата, бу объекттан физик яисә юридик затларга аннан түләүле файдалана алу мөмкинлеген бирү рәвешендә файдаланудан еллык керем проектны гамәлгә ашыручы оешманың «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә билгеләнә торган чыгымнарны каплау срогы дәвамында инвестиция проектын башкаруга бәйле рәвештә алган гомуми кеременнән кимендә 80 процентын тәшкил итсә, түбәндәге чыгымнар каплана:»;

4) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән субсидия һәм әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләнгән салымны кайтару «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы $8^1$ һәм $8^2$ өлешләре нигезендә бирелә.»;

5) 5 өлештә:

а) 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиешле барлык мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чаралары (кулланып булган очракта) дәүләт теркәвенә алынган, һәм, әгәр инвестиция проекты, шул исәптән инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этабы, күчемсез мөлкәт объектларын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне күздә тотса, аларның бөтенесе дә булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүгә таянып билгеләнә торган срокларда файдалануга тапшырылган булса;

2) проектны гамәлгә ашыручы оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, читтән кертелүче таможня пошлиналарын түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;»;

б) 6 пунктта «инвестиция проекты» сүзләрен «үзләренә карата чыгымнар әлеге статья нигезендә капланырга тиешле булган инвестиция проекты» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрүгә вәкаләтле төзелеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы буйсынуындагы дәүләт (бюджет яисә автоном)

учреждениесе тарафыннан үзләренә карата чыгымнар әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 – 3 пунктлары нигезендә капланырга тиешле булган инвестиция проекты кысаларында булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән күчемсез мөлкәт объектларына һәм линия объектларына технологик аудит уздыру турында уңай бәяләмә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән булса;»;

г) түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

«$7^2$) әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактта тотылган чыгымнар турында «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән каралган Федераль казначылык бәяләмәсе бирелгән булса;»;

д) 9 пунктта «турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең башка чаралары» сүзләрен «турыдан-туры дәүләт ярдәме чаралары» сүзләренә алмаштырырга, «турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең бирелгән башка чараларын» сүзләрен «турыдан-туры дәүләт ярдәменең бирелгән чараларын» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 пунктлар өстәргә:

«11) проектны гамәлгә ашыручы оешма капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү нигезендә билгеләнә торган күләмдә һәм срокларда капитал салуларны гамәлгә ашырды;

12) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган инвестиция проектын, шул исәптән инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этапларын гамәлгә ашыру буенча барлык чаралар капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү нигезендә билгеләнә торган срокларда гамәлгә ашырылды (инвестиция проектын, шул исәптән аерым этапларны гамәлгә ашыру кысаларында юридик фактлар гамәлгә керде).»;

6) 6 өлешнең беренче абзацында «чыгымнарны каплау» сүзләреннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә, «гамәлгә ашырылырга мөмкин» сүзләреннән соң «, әгәр мондый этапларның барлык чаралары капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә билгеләнә торган срокларда гамәлгә ашырылса (мондый этаплар кысаларында юридик фактлар гамәлгә керсә)» сүзләрен өстәргә;

7) 7 өлештә «әлеге статьяның 5 өлешендәге 2, 3, 5 – 8 пунктларында каралган шартлар үтәлгән» сүзләреннән соң «, шулай ук капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә билгеләнә торган капитал салуларның күләме һәм сроклары үтәлгән» сүзләрен өстәргә;

8) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Проектны гамәлгә ашыручы оешма чыгымнарны каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 – 7 пунктларында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне, үзләренә карата чыгымнар әлеге статья нигезендә капланырга тиешле булган инвестиция проекты кысаларында булдырылырга (төзелергә) йә реконструкцияләнергә тиеш күчемсез мөлкәт (капиталь төзелеш) объектларының

һәм линия объектларының проект документациясенә һәм аларның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүгә дәүләт экспертизасы уздыру хакындагы уңай бәяләмәне, технологик аудит уздыру турындагы уңай бәяләмәне, шулай ук исемлеге һәм составы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән билгеләнә торган башка документларны җибәрә».»;

9) 16 өлештә «дәүләт ярдәме чарасы күләменнән тыш» сүзләрен «дәүләт ярдәме чарасы күләмен дә кертеп » сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $2^1$ өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), «2021 елның 1 апреленә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 апреленә кадәр, бу датаны да кертеп » сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 2 статьясыннан тыш, 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясы әлеге Законның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1, $1^1$, 3, $4^1$ өлешләре, 5 өлешенең 1, 2, 6, 7, $7^2$ һәм 9 пунктлары, 10 һәм 16 өлешләре (әлеге Закон редакциясендә), «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $2^1$ өлеше (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүләрдән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 ноябрендәге 441-ФЗ номерлы Федераль закон белән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүләр кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына (алга таба – инвестиция проекты) дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү шартлары һәм тәртибе төгәлләштерелде.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертелә.

Аерым алганда, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмаларның төп объектны, шулай ук тәэмин итүче яисә тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (реконструкцияләү, модернизацияләү) өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә чыгымнарын каплау күрсәтелгән заем акчаларына карата турыдан-туры дәүләт ярдәме чаралары бирелмәгән очракта гына гамәлгә ашырыла дип карала.

Устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының турыдан-туры яисә читләтеп катнашу өлеше 25 проценттан артык булган Россия юридик затларына инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары бирелмәячәк дип билгеләнә.

Инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары өлешендә бирелә торган субсидияләрнең һәм түләнгән салымны кайтаруның иң чик күләме турындагы нигезләмә беркетелә.

Оешма чыгымнарын каплау өчен өстәмә шартлар, шул исәптән фактта тотылган чыгымнар турында Федераль казначылык бәяләмәсе булу зарурлыгы да күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.